ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
10.12.2025

КАРАР
№ 1443

2026-2029 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның Комплексны программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә хокук бозулар системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген профилактикалау, системаны ныгыту максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026-2029 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның кушымтада бирелә торган комплексны программасын расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин